**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Кама Тамагы муниципаль районынын**
**Сойки авыл жирлеге**
**Башкарма комитеты**
**Кама Тамагы районы,**
**Сойки авылы**
**тел. 8 (843) 77 36-3-38**
**РТ Камско-Устьинский район с. Сюкеево ул. Колхозная дом 16а**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**Исполнительный комитет**
**Сюкеевского сельского поселения**
**Камско-Устьинский район,**
**с. Сюкеево**
**тел. 8 (843) 77 36-3-38**
**РТ Камско-Устьинский район с. Сюкеево ул. Колхозная дом 16а**

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**2020 елның 9 сентябре** **№6**

«Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге башкарма комитетының «Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге территориясендә кулланыштан чыккан терекөмешле лампаларны кулланучылардан беренчел рәвештә җыю һәм урнаштыру урыннары турында» 2016 елның 17 ноябрендәгее 7 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда контрольдә тоту чараларын үткәргәндә үтәлергә тиешле мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2020 елның 11 июлендәге 1036 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге башкарма комитетының “Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл

җирлеге территориясендә кулланыштан чыккан терекөмешле лампаларын кулланучылардан беренчел рәвештә җыю һәм урнаштыру урыннары турында” 2016 елның 17 ноябрендәге 7 номерлы карарын үз көчен югалткан дип таныргa.

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Сөйки  авылы, Кызыл Армия ур., авыл үзәге;

ТР, Кама Тамагы районы, Сөйки авылы, Колхоз ур., 16 а,китапханә бинасы;

шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Сөйки авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе В.П. Никитин